ШКОЛЬНАЯ ГАЗЕТА «ИКӘН»
МБОУ «ЕСТЕСТВЕННО-НАУЧНЫЙ ЛИЦЕЙ№ 95»
КАЗАН ШӘҺӘРЕ СОВЕТ РАЙОНЫ “95 НЧЕ ЛИЦЕЙ”

# IКӘН

Выпуск № 9 (апрель 2026)

*«Раскрылось небо голубое
Меж облаков в апрельский день.»*
И.Бунин.



***Сегодня в выпуске:***

Путь к звёздам- **стр.1**
Мәктәбебездә Габдулла Тукай көне- **стр.2**
События месяца– **стр.3**
Тукай турында кызыклы фактлар-стр.**4-5**
Проба пера–**стр.6**
“Татарча диктант” акциясе—**стр. 7**
Ярмака добра-**стр.8**
Поздравляем-**стр.8**

***Мәктәбебез тормышы, анда булган яңалыкларга битараф булмаганнар өчен, безнең гәҗитебез кызыклы һәм кирәкле булыр, дип ышанабыз.***

***Гәҗитебезгә язмаларыгызны бастырырга теләсәгез, безгә аларны алып килә аласыз. Без язмаларыгызны бастырып чыгарып, сезгә җиткерербез.***

***Без ай саен сезне гәҗитебезнең яңа саннары белән шатландырырга әзер!( Кабинетыбызның номеры:313/333)***

## Путь к звёздам

Каждый год 12 апреля мы отмечаем День космонавтики — праздник, посвящённый первому полёту человека в космос и достижениям в области космических исследований. В 2026 году этот день особенно важен, ведь человечество продолжает активно исследовать Вселенную и достигает новых высот.

В 1961 году советский космонавт Юрий Гагарин стал первым человеком в истории, совершив орбитальный полёт. С тех пор космические миссии развиваются быстрыми темпами. А каждый 12 апреля напоминает нам о том, как важно стремиться к новым открытиям и знаниям.

В этом году более десятка стран объединились для исследования Луны и Марса. Совместные проекты помогают делиться знаниями и технологиями.

Уже есть первые коммерческие полёты для туристов. Кто бы мог подумать, что летать в космос станут доступнее!

В школах и университетах проходят конкурсы, лекции и мастер-классы, посвящённые космосу. Множество ребят мечтают стать астронавтами и учёными.

Каждое открытие в космосе помогает лучше понять нашу планету, искать решение глобальных проблем и двигаться вперёд. А ещё — вдохновляет молодое поколение на научные свершения!

***День космонавтики — не просто праздник. Это напоминание о том, что человечество всегда движется вперёд, стремясь к звёздам.*** Пусть и в 2026 году наши мечты о космосе станут реальностью!

# Мәктәбебездә Габдулла Тукай көне

Татар халкы үзенең бөек шагыйре Габдулла Тукайны онытмый. Ел саен 26 апрельдә аның туган көнен билгеләп үтә. Ә быел, яраткан язучыбызның 140 еллыгы уңаеннан, республика күләмендә һәм районыбызда күп кенә чаралар уздырылды. Безнең лицеебызда да, укучыларда Г.Тукайның иҗатына кызыксыну тәрбияләү максатыннан, төрле чаралар оештырылды. Укучылар, укытучылар белән бергәләп, язучының әкиятләрен искә төшерделәр, шигырьләрен укыдылар; "Тукай геройлары " дигән темага рәсемнәр ясадылар; әдипнең әсәрләрен өйрәнеп, "Шигырь бәйгесе"ндә катнаштылар. Йомгаклау чарасы буларак, "Тукай - безнең күңелләрдә" дигән әдәби - музыкаль кичә узды. Кичә барышында шагыйрьнең тормыш юлы искә төшерелде, "Кәҗә белән сарык", "Шүрәле һәм Су анасы" әкиятләре сәхнәләштерелде, Тукайга багышланган шигырьләр укылды, җырлар җырланды.









Г.Тукай үзенең иҗат җимешләре аша хезмәтне, табигатьне, кешеләрне яратырга; гадел, мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Ә укучыларыбызның аның әсәрләрен белүләре, кызыксынулары, татарча матур итеп сөйләүләре безнең - укытучыларның күңелендә горурлык һәм якты хис уята.



# Что такое ВПР?

ВПР — это Всероссийские проверочные работы, которые ежегодно проводят в российских школах. Такие работы позволяют проверить, насколько хорошо ученики освоили материал по основным предметам. Для школьников ВПР — это не экзамен, но важный этап, чтобы понять свои знания и подготовиться к будущим испытаниям.



В разное время ученики пишут ВПР по:

- русскому языку,
- математике,
- окружающему миру, истории, обществознанию,

биологии, географии, физике и другим предметам — в зависимости от класса.

Советы по подготовке

1. Повторяйте пройденный материал. Не учите всё заново, а обращайте внимание на сложные темы.
2. Пробуйте решать варианты прошлых лет. Это поможет узнать формат заданий и развить уверенность.
3. Не переживайте слишком сильно! ВПР — это не экзамен, а этап самооценки.
4. Обращайте внимание на свои ошибки. Разбирайте их вместе с учителем.

Поддерживайте распорядок дня. Здоровый сон и питание очень важны при умственных нагрузках.


Для родителей

- Поддержите ребёнка: объясните, что ВПР — это возможность узнать свои сильные и слабые стороны.
- Помогите организовать время для повторения, но не заставляйте заниматься слишком много.

Сохраняйте спокойствие: дети всегда чувствуют настроение взрослых!

ВПР — важная часть учебного года, которая помогает расти и ученикам, и учителям. Пусть проверочные работы станут стартовой площадкой для новых знаний и побед!

# Тукай турында кызыклы фактлар




И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

*Быел милләтебезнең бөек шагыйре Габдулла әфәнде Тукаев туууына 140 ел була. Якты дөньяда 26 ел гомер кичереп бакыйлыкка күчкән шагыйрь турында без ниләр беләбез, аның тормыш һәм иҗат юлында нинди кызыклы фактлар булган. Әлеге язмада шулар турында язып узасыбыз килә.*

1.Тукайның кечкенә вакыттагы фотосурәтләре сакланмаган, дөресрәге, балачакта ул фотога төшмәгән, чөнки ул чорда авылларда фотограф булмаган. Шагыйрь 1903 елда унҗиде яшендә беренче тапкыр объектив каршына басарга җөрьәт итә. Тукай фотога төшәргә яратмаса да, архивларда шагыйрьнең 2 дистәгә якын фотосы бар.

2.Язылган һәр шигырь юлы өчен Габдулла Тукайга 50 тиен көмеш яисә алтын белән түли торган булганнар. Үз заманында Тукаев иң күп түләнүчән шагыйрь булып исәпләнгән.

3.Габдулла Тукай үз язмаларын газета-журналларга биргән вакытта төрле тәхәллүсләр (псевдоним) кулланган. Бүгенге көндә галимнәр Тукайның үз мәкаләләрен имзалаганда 70кә якын тәхәллүсе булуын дәлиллиләр. Алар арасында: “Кырмыска”, “Шүрәле”, “Тәртә башы”, “Догачы”, “Каз”, “Бер фикерче”, “Биик усал”, “Болгар”, “Имзасыз да Яраретдинов”, “Милләтче”, “Мин язмадым”, “Мылтык”, “Мәҗнүн”, “Мөсафир”, “Салам Торхан”, “Счет төймәсе”, “Сөңге”, “Уральск кешесе”, “Хәйләсез”, “Чапансыз”, “Шәкерт угы”, “Җен” һ.б. имзалар бар.

4.Габдулла Тукай татар, гарәп, фарсы, төрек һәм урыс телләрендә иркекле аралаша һәм яза белгән.

5.Замандашлары сөйләве буенча Габдулла Тукай кием-салымга артык игътибар итмәгән. Шагыйрь тормышыннан шундый вакыйга билгеле: базардан яңа пиджак алгач, аның 2 размерга зуррак булуына карамастан, ул аны бер дә кыенсынмыйча, шактый озак кына киеп йөргән.

6.Габдулла Тукай халык җырларын бик тә яраткан һәм аларны җыю буенча да шактый гына эшләр башкарган. Шагыйрь 1910 елда “Шүрәле” тәхәллүсе белән имзаланган “Халык моңнары” дип исемләнгән, үз эченә 28 җырны туплаган китап бастырып чыгара.

7.1906-1907 нче елларда «Әл-гаср әл-җәдид» («Яңа гасыр») журналында Габдулла Тукай Иван Крыловның 65 мәсәлен тәрҗемә итеп бастыра.

8.Габдулла Тукайның Казанда “Болгар” кунакханәсенең 40нчы бүлмәсендә яшәгәне күпләргә мәгълүм, әмма Тукай әлеге кунакханәдән тыш 1907 елда “Сарай” кунакханәсе номерларында (Париж Коммунасы урамы, 9 нчы йорт), соңрак кыска гына вакыт “Свет” кунакханәсендә, ә 1912-1913 елларда “Амур” кунакханәсе (Мәскәү урамы, 70 нче йорт).



9. Тукай тормышында хатын-кызлар күп булганмы? Җаектә яшәгән елларында Тукайның ошатып йөргән 2-3 туташы булуын язалар һәм аларның барысының да исемнәре Фатыйма булуын искәртәләр. Ә инде Казанга күченеп килгәч, шагыйрь күңеленә һәм иҗатына йогынты ясаган туташлар исемлегендә бары тик Зәйтүнә Мәүлүдова гына була. Зәйтүнә Тукайның замандашы һәм дусты – язучы Фатих Әмирханга туган тиешле була. Шуңа күрә Тукай белән Зәйтүнәнең танышуына сәбәпче кеше дә – Фатих Әмирхан. Тукай белән Зәйтүнә өч мәртәбә очрашалар. Һәр очрашу кыенлык белән уза: Тукай йә чыгып китә, йә салкынлык күрсәтә. Ләкин бер кичә алдыннан ул Зәйтүнәгә контрамаркамы, билетмы бирә, очрашырга сөйләшәләр, ләкин очраша алмыйлар. Зәйтүнә Казаннан күченеп киткәндә Тукай аны озатырга төшмәкче була, ләкин соңарган дип әйтәләр, ул пристаньга төшә алмый. Бер яктан, Тукай Зәйтүнәгә һич тә битараф булмаган, икенче яктан, сәламәтлеге булмау, күзендәге табы аркасында мәхәббәт хисләрен куертудан үзен-үзе тыеп торган.

10.Тукай вафат булу алдыннан нәширләрдән алырга тиешле булган 500 сум акчасын 2 сәләтле баланы рус уку йортларында белем алыр өчен сарыф итәргә дип васыять итә. Шулай ук 1913 елда Петербургның мөселман хәйриячәлек җәмгыяте вафат булган Габдулла Тукаев истәлегенә сәләтле балалар өчен һәркайсы 100әр сум булган махсус 2 стипендия булдыра.

11.Шагыйрьнең үзе исән чакта 22 исемдә 46 китабы нәшер ителгән. Ә 1917 нче елга кадәр Тукайның 72 китабы 221900 нөсхәдә нәшер ителгән.

12.Тукай вафат булган көнне Казанда рәсми булмаган матәм көне игълан ителә. Шәһәрдәге кибетләр, заводлар эшләмәгән. Фабрикаларда кыска эш көне игълан ителгән. Бу көнне мәктәп-мәдрәсәләрдә укулар туктатылган. Ул заман өчен хатын-кызларның зиратка баруы тыелган булуга карамастан, татар хатын-кызлары гимназиясен оештыручы Фатиха Аитова укучы кызларга Тукайны күмәргә барырга рөхсәт бирә.

13.Тукай вафатыннан соң Казанда тышлыкларына Тукай сурәте төшерелгән конфетлар, шәм, сабын чыгара башлаганнар. Тукай музеендагы экспонатлар арасында шагыйрь сурәте төшерелгән конфет тышлыгын әле дә күреп була. Әлеге конфетларны Казан сәүдәгәре Вәлиулла Ибраһимовның Шамил йортында урнашкан "Альфа" кондитер фабрикасы чыгарган (1913).

14.Шагыйрьнең вафатыннан соң аның йөзеннән гипс битлек төшереп алынган, бүгенге көндә ул Казандагы Г.Тукай Әдәби музеенда саклана. Бу битлекнең язмышы бик үзенчәлекле. Аны 1958 елда Мөлеков атлы бер Алмата кешесе СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы – Тел, әдәбият һәм тарих институтына алып килә. Ул әлеге битлекне 30нчы елларда Оренбургта Гыйльметдин Шәрәфнең бертуганы Борһан Шәрәф биргәнен әйтә. Берникадәр вакыттан соң битлекне Дәүләт музеена тапшыралар, анда ул утыз ел саклана. 1988 елның апрелендә, Тукайның вафаты көнендә, битлекне музейга килүчеләргә күрсәтәләр.

Үз вакытында Дәүләт музееның әдәби экспозицияләр бүлеге хезмәткәрләре – сынчылар Садри Ахун һәм Баки Урманче битлекне өйрәнеп, аның чыннан да шагыйрьнең йөз чалымнарын тулысынча күчерүен белдерә. Баки Урманче гасыр башында мондый битлекләрне гадәттә Казан университетының медицина факультеты студентлары төшергәнлеген хәбәр итә. Шагыйрьнең йөзеннән гипс битлек төшереп алу хәстәрен кем оештырган? Сораулар күп. Шунысы аңлашыла: Тукайның якын дусларыннан берәү аның кадерле чалымнарын киләчәк буыннар өчен саклап калырга теләгән. Бәлки, Фатих Әмирхандыр? 1926 елга кадәр, ягъни Фатих Әмирханның вафатына кадәр, бу битлек аңарда сакланган дигән фаразлар бар.

15.Казан шәһәрендә Габдулла Тукайның өч һәйкәле бар. Аның берсе Тукай исемен йөртә торган скверда, икенчесе М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры бинасы янында һәм өченчесе шагыйрьнең җәсәде күмелгән Яңа татар бистәсе зиратында.

# Проба пера

Давным-давно, когда звёзды казались ещё ближе, а мечты о полётах к ним — почти несбыточными, жил на Земле отважный лётчик по имени Юрий Гагарин. Он очень любил смотреть в ночное небо и думать: «А что там, за этой бескрайней синевой? Какие чудеса прячут далёкие планеты?»



Однажды ночью, когда Луна светила особенно ярко, а звёзды мерцали, словно подмигивая, Юрий вышел на поле, лёг на мягкую траву и засмотрелся на небосвод. Вдруг он услышал нежный голос:

— Юрий, ты готов отправиться в путешествие, какого ещё не знал человек?

Он оглянулся — рядом стояла загадочная женщина в серебристом платье, переливающемся, как Млечный Путь. Это была сама Звезда Мечты.

— Я готова показать тебе чудеса Вселенной, — сказала она. — Но помни: главное — не потерять связь с Землёй, с её теплом и добротой.

Юрий кивнул, встал, и в тот же миг они взмыли в небо, оставив внизу огни деревень и городов.

Сначала они оказались у Луны. Она оказалась не просто холодным камнем, а местом, где жили лунные кролики, прыгавшие между кратерами и собирающие лунный свет в маленькие ведёрки. Кролики показали Юрию, как свет Луны помогает растениям расти даже в самых тёмных уголках космоса.

Затем их путь лежал к Марсу. Там, среди красных песков, Юрий встретил марсианских садовников — маленьких существ в прозрачных шлемах, которые выращивали удивительные кристаллы, светящиеся всеми цветами радуги. Они подарили Юрию один кристалл со словами:

— Пусть он напоминает тебе, что красота есть везде, даже там, где её не ждёшь.

Дальше путь лежал к гигантскому Юпитеру. Его вихри и полосы завораживали, а спутники кружились вокруг, словно дети вокруг мамы. Один из спутников, весёлый и озорной, шепнул Юрию.

Наконец, Звезда Мечты и Юрий оказались на краю Солнечной системы. Отсюда Земля казалась крошечной голубой точкой, хрупкой и невероятно красивой. Юрий почувствовал, как сильно он любит свой дом, свою планету.



— Теперь ты видишь, — сказала Звезда Мечты, — насколько важна Земля. Ты должен рассказать людям, что мы все — одна семья, живущая на этом чудесном острове в океане космоса.

В тот же миг Юрий оказался снова на поле, на знакомой траве. Было раннее утро, первые лучи солнца золотили росу. Но теперь он знал: космос — не просто пустота и звёзды. Это место чудес, открытий и важных уроков.

Прошло немного времени, и Юрий Гагарин стал первым человеком, покорившим космос на настоящем корабле. Он облетел Землю по орбите и вернулся домой, подтвердив то, что узнал в своём волшебном путешествии: наша планета прекрасна, и её нужно беречь.

С тех пор все дети знают имя Юрия Гагарина — человека, который не только первым увидел Землю из космоса, но и принёс людям весть о том, что Вселенная полна чудес, а главное чудо — наша голубая планета ЗЕМЛЯ.

*Ахмадуллина Дильбар, ученица 6 б класса.*

# “Татарча диктант” акциясе



Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан 2026 ел татар дөньясы өчен Габдулла Тукай елы дип игълан ителде. Шул уңайдан агымдагы елның 24 -26 апрель көннәрендә унберенче тапкыр Дөньякүләм «Татарча диктант» белем тикшерү акциясе бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 140 еллыгына багышланып уздырылды.

Чараның төп максаты – татар телен саклау һәм аны киң җәмәгатьчелек арасында популярлаштыру, грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту, шулай ук татар халкының милли үзаңын һәм мәдәни үзенчәлеген ныгыту.




Бу масштаблы чара татар теленә битараф булмаган безнең лицеебыз укытучыларын һәм укучыларын да берләштерде.

Алар диктант язып, татар теленә карата хөрмәтен, мәхәббәтен күрсәттеләр.

«Татарча диктант» акциясе традицион рәвештә «Туган тел» җырын башкару белән тәмамланды.

**Республиканский семинар-стажировка по татарскому языку и литературе** в нашем лицее!

8 апреля наш лицей с гордостью принял участников республиканского семинара-стажировки педагогических работников, реализующих общеобразовательные программы по татарскому языку и литературе

Это был насыщенный и вдохновляющий день!

Наши учителя-лицеисты провели открытые уроки на татарском языке, продемонстрировав современные подходы к обучению и глубокое уважение к родной культуре. Педагоги делились своим опытом, проводили мастер-классы, где каждый мог почерпнуть новые идеи и методики для работы с детьми.

Завершился семинар настоящим творческим праздником — для гостей был организован концерт, в котором прозвучали национальные песни, стихи и яркие танцевальные номера. Атмосфера тепла, дружбы и любви к татарскому языку объединила всех участников!



Мы гордимся нашими учителями и благодарим гостей за активное участие и поддержку! Такие события — важный вклад в развитие образования и сохранение культурного наследия.

## Поздравляем

*Мирзоева Айтадж Эльмановна, учитель математики ( 4 апреля)*
*Гатиятуллина Юлия Александровна, учитель английского языка ( 9 апреля)*
*Лавренюк Светлана Андреевна, секретарь( 15 апреля)*
*Миргасимова Рамзия Бильсуровна, учитель начальных классов ( 16 апреля)*
*Евлеева Марина Васильевна, учитель начальных классов (19 апреля)*
*Юнусова Альбина Альбертовна, учитель начальных классов (19 апреля)*
*Волкова Роза Николаевна, учитель начальных классов (21 апреля)*
*Насибуллина Гузалия Равиловна, учитель родного языка (27 апреля)*

# *Весенняя ярмарка добра в нашей школе: вместе ради светлого будущего.*



Весна — время обновления и надежды, и наша школа решила отпраздновать эти чувства, организовав яркую и добрую традицию — весеннюю ярмарку добра!

Это ежегодное мероприятие, где учащиеся, родители и учителя объединяются для сбора средств на благотворительные цели. Все вырученные деньги помогают нуждающимся, поддерживают школьные проекты и делают наш город чуть светлее

Такие мероприятия учат детей заботиться о других, развивают в них чувство командного духа и ответственности. Кроме того, ярмарка — это отличный способ провести время вместе, познакомиться с соседями и почувствовать себя частью доброй и дружной семьи.



**Благодарим всех участников!**

**Редакциянең адресы:**
Казан шәһәре,
Азат Аббасов, 15 нче йорт
Тел. 89050229576
**Тираж** – 10 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы
Нурмухамедова Регина Викторовна
**Редколлегия әгъзалары:**
Агзамова Зиля, Ахметзянова Риана, Багманов Искандер, Габитова Диляра, Гизатуллин Аяз, Гильмутдинова Зарина, Замалутдинова Самира, Исламгараева Амина, Исмагилов Карим, Каюмова Амалия, Леонтьева Екатерина, Нугманова Амалия, Леонтьева Екатерина,Каюмова Амалия, Садыгов Тагир, Бадретдинова Амина, Фадеев Амир, Кукарская Маргарита, Хаертдинова Риана, Суворова Таисия, Зайцева Екатерина, Хабибуллина Айлана, Ахмадуллина Дильбар.